| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2021 Баулы шәһәре № 24

Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләт урман фондының җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны рациональ файдалану, аларны саклау һәм яңадан үстерү максатларында Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымтадагы Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләт урман фондының җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Татарстан Республикасы
Баулы шәһәр Советының 2021 елның
18.02.2021 24нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләт урман фондының җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 15 статьясы, Россия Федерациясе Урман кодексы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 61, 68, 77 статьялары нигезендә халыкның экологик иминлеген тәэмин итү максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибен билгели.

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Яшел утыртмалар – табигый үскән һәм махсус утыртылган агач, куак һәм үләнчел үсемлекләр (паркларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәклекләрне, шулай ук аерым торучы агачларны һәм куакларны да кертеп).

Табигать территорияләре - хуҗалык эшчәнлеге алып барылмаган яки аз алып барылган, бердәм географик (климат) шартларында формалашкан, үз эченә җирлек рельефының, туфрак, үсемлекләрнең билгеле бер типларын алган территорияләр.

Яшелләндерелгән территорияләр - табигый үскән үсемлекле участоклар урнашкан территорияләр, махсус булдырылган яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрдәге аз төзелешле, алар чикләрендә өслекнең 50 процентыннан да ким булмаган өлеше үсемлекле участоклар.

Урманлы территорияләр - табигый үскән урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигать территорияләре участоклары.

Агач - диаметры 1,3 м биеклектә кимендә 5 см ачык беленеп торган кәүсәле үсемлек, үсентеләрдән кала.

Куаклык - туфрак өслегендә тармакланган (агачтан аермалы буларак) күпьеллык үсемлек.

Үлән капламы - газон, табигый үлән үсемлекләре.

Әрәмәлек - нинди дә булса урында куе булып үсә торган үсемлекләр, куаклар.

Яшел массив - 50 данәдән дә ким булмаган зур агач (15 яшьтән өлкәнрәкләр) үсә торган территория участогы.

Яшел утыртмаларны зарарлау - аларның үсешен туктатуга китерми торган, шул исәптән ботакларның, тамыр системасының механик зарарлануына, кайрының бөтенлеген бозуга, туфракның тере катламын бозуга, яшел үсентеләрнең я туфракның зарарлы матдәләр белән пычрануына, ут төртүгә яисә башка йогынты ясауга сәбәпле яшел утыртмаларга зыян китерү.

Яшел утыртмаларны юкка чыгару (югалту) - яшел утыртмаларны кисү яки аларның үсешен туктатуга китергән башка төрле зарарланулар.

Компенсацион яшелләндерү - юкка чыгарылган яисә 2 коэффиценты белән зарарланган яшел утыртмаларны торгызу.

## 2. Яшел утыртмаларны саклауның төп принциплары

2.1. Муниципаль берәмлек территориясендә үсә торган яшел утыртмалар саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкара һәм сакланырга тиеш.

2.2. Муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан барлык яшел утыртмалар (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш).

2.3. Муниципаль берәмлек территориясендә яшел утыртмаларның сакланышын һәм үсеш шартларын тәэмин итү бурычлары түбәндәгеләргә йөкләнә:

- оешмаларга үзләре беркетелгән эшчәнлек төрләрен тормышка ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә - әлеге оешмалар җитәкчеләренә;

- милекчелектәге яки арендадагы участокларда- милекчеләр яки арендаторларга - юридик затларга һәм гражданнарга.

2.4. Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, файдаланучылары һәм арендаторлары яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәргә, яшел утыртмаларны тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.

2.5. Әлеге Нигезләмә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, муниципаль берәмлек территориясендә агач-куак үсентеләрен кисүгә бәйле проектлауны, төзүне, ремонтлауны һәм башка эшләрне алып баручы барлык гражданнарга һәм оешмаларга кагыла.

2.6. Муниципаль берәмлек территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2.7. Җир кишәрлеген сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документациясендә яшел утыртмаларның торышы

турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысын тулысынча бәяләү булырга тиеш.

2.8. Яшелләндерелгән территорияләрен һәм яшел массивларны яшел утыртмаларның тереклеген тәэмин итмәгән куллану рөхсәт ителми.

3. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

3.1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны рөхсәтсез кисү тыела.

3.2. Муниципаль берәмлек территориясендә агач һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла. Кисүгә рөхсәт Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) җитәкчесе күрсәтмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.3. Яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарма комитет җитәкчесе исеменә билгеләнгән рәвештә гариза бирә (әлеге Нигезләмәгә 1нче кушымта), анда утыртмаларның саны, исеме, аларның торышы, чикләнгән кисүне үткәрү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелә.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- шәхесне раслаучы документ;

- вәкилнең вәкаләтләрен (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш итсә) раслый торган документ;

- якындагы корылмаларга кадәр участок схемасы яисә киселергә тиешле яшел утыртмалар төшерелгән башка ориентирлар;

- җир участогы Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса, җир участогына хокук билгели торган һәм аларны раслый торган документларның таныкланган күчермәләре;

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы турында белешмәләр, авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми (билгеләнә);

- биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга туры килә торган яшел утыртмаларны кисү башкарылган очракта, расланган проект документациясе;

- территорияләрнең хуҗалары белән яшел утыртмаларны кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү;

- яшел утыртмаларны утыртканда яисә күчереп утыртканда, инженерлык челтәрләре вәкилләре белән (җир эшләрен уздыруга ордер алып) килештерү.

3.4. Башкарма комитет, заявка-хат килгәннән соң, мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләрне алу өчен, әлеге эш төрен үткәрүгә рөхсәте булган махсуслаштырылган

оешмага мөрәҗәгать итәргә киңәш итә:

- яшел утыртмаларның исәбе ведомосте;

- киселергә тиешле агач-куак утыртмаларының санын, төрен, категориясен билгеләү максатында төзелә торган яшел утыртмаларны табигый техник тикшерү акты;

- киселгән агач өчен бәя (түләү) исәбе. Киселгән агач өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган ставкалар нигезендә аерым исәпләнә.

Югарыда күрсәтелгән эшләр мөрәҗәгать итүче хисабына башкарыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты - 90 көн.

3.5. Башкарма комитет мөрәҗәгать итүченең гаризасы, яшел утыртмаларны табигый техник тикшерү акты, киселгән агач өчен бәяне (түләүне) исәпләп чыгару нигезендә башкарма комитет җитәкчесенең муниципаль берәмлек территориясендә яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт бирү турында күрсәтмәсе проектын әзерли.

3.6. Эш башкаруга рөхсәт алганда, яшел утыртмаларны кисү турында мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларны кискән өчен түләүләр кертергә һәм компенсация яшелләндерүнең үткәреләчәген раслый торган документларны тапшырырга тиеш.

3.7. Агач һәм куакларны кискән өчен түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына күчерелә.

3.8. Яшел утыртмаларны кисү эшләре билгеләнгән нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә мөрәҗәгать итүче акчалары исәбенә башкарыла. Агач кисү бары тик аттестация узган белгечләр тарафыннан гына рөхсәт ителә.

3.9. Киселгән яшел утыртмаларның тамырларын алу, төяү һәм алып китү эш башлаган вакыттан алып мөрәҗәгать итүче хисабына өч көн эчендә башкарыла. Киселгән яшел утыртмаларны эш урынында тоту тыела.

3.10. Утыртмалар киселгән территория янәшәсендәге газон, яшел утыртмалар зарарланган очракта, эш башкаручы аларны, үз компетенциясе чикләрендә территория хуҗасы һәм контроль органнары белән килештерелгән, әмма зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, аларны мәҗбүри рәвештә яңадан торгызу эшләрен башкара.

3.11. Агачны кискән өчен түләмичә агач һәм куакларны кисү башкарма комитет тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

- территорияне җыештыру, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү өчен яшел утыртмаларны кисү;

- аварияне һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау;

- Дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм иҗтимагый биналарда яктылык режимын боза торган агач һәм куакларны кисү;

- һәлакәт китереп чыгарырга мөмкин агачларны һәм куакларны (аву куркынычы тудыручы, корыган агачларны) кисү.

3.12. Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел утыртмаларны кисүне тормышка ашыручы мөрәҗәгать итүчегә башкарма комитет белән килештерелгән урыннарда компенсация яшелләндерү үткәрергә кирәк.

3.13. Коры-сары һәм хәвеф-хәтәр тудырырга мөмкин үсентеләр әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә акт нигезендә комиссияләр тикшерүе нигезендә киселә.

3.14. Россия Федерациясе Урман кодексының 20 маддәсе аналогиясе буенча, хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән яисә аны гражданга яисә юридик затка милеккә тапшырганнан соң җир кишәрлегендә табигый рәвештә барлыкка килгән агач-куак үсемлекләре аның үз милке булып тора, ул аны үз карамагында файдалана ала.

3.15. Түбәндәгеләр яшел утыртмаларны санкцияләнмәгән кисү яисә юкка чыгару дип таныла:

- рөхсәтсез кисү яисә рөхсәттә күрсәтелмәгән агачларны һәм куакларны кисү;

- ут белән яндыру яисә саксыз эш итү нәтиҗәсендә агачларны һәм куакларны юк итү яки зарарлау;

- кәүсәнең әйләндереп алу яки кисү;

- агачларның һәм куакларның үсүе туктатуга китергән зарарлау;

- агачларның һәм куакларның агынты сулар, химик матдәләр, калдыклар һәм башкалар тарафыннан зарарлануы;

- корыган агачларны рөхсәтсез кисү;

- үсә торган агачларның һәм куакларның башкача зарарланулары.

3.16. Дәүләт урман фондында урнашкан агачларны һәм куакларны кисү махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан бирелгән рөхсәтләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.17. Әлеге Нигезләмәне бозып, агачларны һәм куакларны кисү үз белдеге белән кисү булып тора һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш. Әлеге Нигезләмә кагыйдәләрен үтәү муниципаль берәмлек территориясендәге барлык гражданнар, оешмалар һәм учреждениеләр өчен мәҗбүри.

## 4. Компенсацион яшелләндерү

4.1. Компенсацион яшелләндерү рөхсәт ителгән кисүләр, яшел үсентеләрне законсыз зарарлау яки юкка чыгару очракларында тормышка ашырыла. Компенсацион

яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен яраклы якындагы сезонда, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару факты билгеләнгән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2. Компенсацион яшелләндерү утыртмаларны кисүдән файда алган яки аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә зарарланган гражданнарның яисә юридик затлар акчалары исәбеннән башкарыла.

4.3. Әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларга китерелгән зыян натураль формада - компенсация рәвешендә капланырга тиеш: 2 коэффициенты белән юкка чыгарылганнарга алмашка яшел утыртмалар утыртыла.

5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашырганда
яшел утыртмаларны саклау

5.1. Муниципаль берәмлектә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру яшел утыртмаларны яклау таләпләрен үтәп алып барыла.

5.2. Яшелләндерелгән территорияләрдә, шул исәптән яшел массивларда, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир участокларында төзелеш алып барылырга, аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган төрдә кулланылырга тиеш түгел.

5.3. Яшел утыртмалар үскән җир участокларында төзелеш оештырганда, проектка кадәрге документациядә киселергә тиешле яшел үсентеләрне бәяләү булырга тиеш. Мондый очракларда зыянны каплау киселгән агач өчен һәм әлеге Нигезләмәнең 2нче һәм 3нче бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә компенсацион яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашырганда
яшел утыртмаларны саклау

6.1. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда сәүдә һәм башка эшкуарлык эшчәнлеге, башкарма комитет рөхсәтеннән башка эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашыру өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда тормышка ашырганда шартлау куркынычы булган, янгын куркынычы булган һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел утыртмаларны зарарлауга яисә юкка чыгаруга китерергә сәләтле башка гамәлләр тыела.

7. Административ җаваплылык

7.1. Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавап тоталар.

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге территориясендәге
Россия Федерациясе дәүләт урман
фондының җирләренә һәм физик һәм
юридик затларның хосусый милкендәге
җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны
тәртибе турындниFгезләмәгә
1нче кушымта

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
җитәкчесенә
________________________________
____________________________________
____________________________________
(оешманың исемен яки Ф.И.О., адресын күрсәтергә)

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге агач-куак үсемлекләрен чикләнгән кисүгә гариза

Түбәндәге җир участогындагы агачларны, куакларны, агач-куаклыкны (кирәклесенең астына сызарга) кисәргә рөхсәт итүегезне сорыйм

___________________________________________________________________________

_______________________________________________________________

(оешманың исемен яисә Ф.И.О. җир кишәрлегенә хокукның төрен күрсәтергә)

__________________________________________________________урнашкан.

Җир участогында:

______________________________ данә агач.

___________________________ данә куаклык.

Җир участогын үзләштерү һәм төзекләндерү процессында агачны кискән өчен түләргә һәм дендроплан нигезендә агач-куак үсентеләрен компенсацион яшелләндерү эшен үткәрергә сүз бирәм.

.

__________________________ ___________________

Ф.И.О. (Имза) (Дата)

Кушымталар:

1. Башлангыч рөхсәт кәгазьләре.

2. Кисү күздә тотыла торган яшел утыртмаларның төрен һәм санын алган җир кишәрлеге планы.

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге территориясендәге
Россия Федерациясе дәүләт урман
фондының җирләренә һәм физик һәм
юридик затларның хосусый милкендәге
җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны
тәртибе турынднигезләмәгә
2нче кушымта

Яшел утрытмаларны киселергә тиешле дип табу турында
акт

«_____»_________ ________ ел

Түбәндәге составта комиссия:

1.____________________________________________________________

(Ф. И. О. вазыйфа)

2.____________________________________________________________

(Ф. И. О. вазыйфа)

3.____________________________________________________________

(Ф. И. О., вазыйфа)

Яшел утыртмаларны тикшерү эшен башкарды.

Тикшерү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр билгеләнде:

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

Нәтиҗә:

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

Комиссия әгъзаләре:

1. ______________________ ______________________
(имза) (Ф. И. О.)

2. ______________________ ______________________
(имза) (Ф. И. О.)

3. ______________________ ______________________
(имза) (Ф. И. О.)